БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 01» сентябрь 2021 ел № 270

Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының Балтач звеносы турында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы турында» 2003 елның 30 декабрендәге 794 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында» 2004 елның 10 ноябрендәге 480 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының Балтач звеносы эшчәнлеген алга таба камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы район башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбәндәге кушымта итеп бирелгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының Балтач звеносы турында нигезләмәне (1 нче кушымта);

Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының Балтач звеносы көчләре составын һәм даими әзерлек чараларын (2 нче кушымта);

Балтач муниципаль районы хезмәтләрен һәм оешмаларын һәм аларның Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының Балтач звеносы эшләвен тәэмин итү буенча функцияләре исемлеген (3 нче кушымта).

2. Балтач муниципаль районы оешмалары, предприятиеләре һәм учреждениеләре җитәкчеләренә милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының объектлар звенолары турында нигезләмәләрне расларга һәм аларның эшен оештырырга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан

Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов